ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«31» июль 2023ел № 656

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында нәтиҗә әзерләү өчен нигез булып хезмәт иткән фикер каршылыкларын җайга салу буенча килештерү комиссиясе төзү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында нәтиҗә әзерләү һәм аның составын раслау өчен нигез булып хезмәт иткән фикер каршылыкларын җайга салу буенча килештерү комиссиясе төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

2. Килештерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибен расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Ә. Кадыйровка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Гатиятов

1 нче кушымта
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«31» 07 2023 ел, № 656
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында нәтиҗә әзерләү өчен нигез булып хезмәт иткән фикер каршылыкларын җайга салу буенча килештерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Галимуллин И.Ә. | Комиссия рәисе, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Кадыйров И.Ә. | Комиссия секретаре, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Сираҗиев И.Г. | Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе |
| Касыймов Р.Ф. | «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| Вәкил | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (килешү буенча) |
| Вәкил | «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе (килешү буенча) |

2 нче кушымта
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«31» 07 2023 ел, № 656
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында нәтиҗә әзерләү өчен нигез булып хезмәт иткән фикер каршылыкларын җайга салу буенча килештерү комиссиясенең эшчәнлек тәртибе

1. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге Федераль Законына, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә килештерү комиссиясе составын һәм эш тәртибен раслау турында» 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгы боерыгына таяна.

2. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара хезмәттәшлектә алып бара.

3. Килештерү комиссиясе төзелгәннән соң ике айдан да артык эшләми.

4. Килештерү комиссиясе утырышын килештерү комиссиясе рәисе оештыра һәм алып бара.

5. Килештерү комиссиясе утырышларында комиссия әгъзалары катнаша, ә кирәк булганда, гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә килештерү комиссиясе утырышларында башка органнар вәкилләре катнаша ала.

6. Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә рәис һәм секретарь кул куя.

7. Килештерү комиссиясе кабул иткән карарга каршы тавыш биргән килештерү комиссиясе әгъзалары беркетмәгә теркәлә торган һәм аның аерылгысыз өлеше булган аерым фикер әйтә ала.

8. Килештерү комиссиясе карары утырышта катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышлары белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, килештерү комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

9. Килештерү комиссиясе эшенең нәтиҗәләре килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсендә чагыла.

10. Эш нәтиҗәләре буенча килештерү комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

10.1. Территориаль планлаштыру документының проектын әлеге проект белән килешмәү өчен нигез булган барлык искәрмәләрне исәпкә алып, аңа үзгәрешләр керткәннән соң килештерү;

10.2. Баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып хезмәт иткән сәбәпләрне күрсәтеп, территориаль планлаштыру документының проектын килештерүдән баш тарту.

11. Килештерү комиссиясе эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләрне тапшыра:

11.1. Тәртипнең 10 пунктының 10.1 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, текст формасындагы материаллар һәм килештерелмәгән мәсьәләләр буенча карталар рәвешендә аңа кертелгән үзгәрешләр белән территориаль планлаштыру документы проекты.

11.2 Тәртипнең 10 пунктындагы 10.2 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, территориаль планлаштыру документының килештерелмәгән проекты, территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында нәтиҗә, килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, шулай ук килештерелмәгән мәсьәләләр буенча текст һәм карта рәвешендәге материаллар.

10 пунктның 10.2 пунктчасында күрсәтелгән документлар һәм материаллар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Килештерелмәгән мәсьәләләр буенча материалларны территориаль планлаштыру документы проектыннан төшереп калдыру турында тәкъдимнәр (шул исәптән килештерелмәгән мәсьәләләрне килештергәнчегә кадәр теркәү максатыннан, аларны тиешле картада күрсәтү юлы белән);

Мондый территориаль планлаштыру документына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдимнәрен әзерләү юлы белән территориаль планлаштыру документын раслаганнан соң 11 нче пунктның 11 нче пунктчасында күрсәтелгән сорауларны килештерү планы.

12. Килештерү комиссиясе тәкъдим иткән материаллар һәм беркетмәләр нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе килештерелгән яки билгеле бер өлештә килештерелмәгән проектны раслауга яки раслаудан баш тартуга һәм аны эшләп бетерүгә җибәрә.

13. Килештерү комиссиясе адресына язма рәвештә килгән гаризаларга һәм сорауларга җаваплар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокларда бирелә.

14. Килештерү комиссиясе карарлары Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителергә мөмкин.